# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкиноавыл җирлегендә Ерепкино авылында халык үзара салымын кертү турында.

«20» ноября 2019 года № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегендә Ерепкино авылында халык җыены карар итте:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Ерепкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

**- Ерепкино авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата:**

-кышкы чорда поселок эчендәге автомобиль юлларын карап тоту);

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш, грунтлау, ком һәм вак таш салу) авыл урамнарын.

**- Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- Ерепкино авылында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерлар сатып алу.

Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә су белән тәэмин итү, су бүлү, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- Ерепкино авылында тирән насосны ремонтлау һәм алыштыру.

**- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.**

3. Әлеге карарны Иске Тимошкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендә урнашкан рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы: Ф.Н. Степанов